

Яна ел бәйрәмнәре алдыннан Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Матбугат үзәгендә Кышкы каникуллар вакытында балалар куркынычсызлыгын профилактикалауга багышланган матбугат конференциясе узды. Чарада Мордовия эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат һәм ижтимагый элемтәләр бүлеге башлыгы, эчке хезмәт полковнигы Светлана Холодкова, Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте кагыйдәләре эшчәнлеген оештыру бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы Алексей Киреев, республика Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәре полиция капитаны Ольга Аносова, Россия тикшерү комитетының Мордовия Республикасы буенча тикшерү идарәсе вәкиле Наталья Афанасьева, шулай ук ведомство каршындагы Ижтимагый совет әгъзасы Максим Захаров катнашты. Чараны ачып, Алексей Киреев, кагыйдә буларак, каникул вакыты житү белән яшүсмерләрнең бик күп буш вакыты барлыкка килүен билгеләп үтте.       Берникадәр дәрәҗәдә барысы да ата-аналар контроле мөмкинлеге булмау белән катлаулана. «Каникуллар безнең балаларга файда булсын һәм тискәре хәлләр белән карангыланмасын өчен, аларның ялын дөрес оештыру кирәк. Олкәннәр, һичшиксез, балалар белән аңлату эшләре алып барырга, шул исәптән хокукка каршы гамәлләр өчен җаваплылык, шулай ук нинди дә булса штаттан тыш хәлләрдә эш итү алгоритмнары турында сөйләргә тиеш, - диде ул. - Тимер юл транспорты объектларында, сулыкларда, җәмәгать урыннарында, шулай ук пиротехник әйберләрдән файдалану кагыйдәләрен аңлатырга кирәк. Урамда яки җәмәгать урыннарында табылган банк картасының шәхси максатларда кулланылмавы фактын игътибарсыз калдырмаска».
Моннан тыш, спикер балигъ булмаганнарга экстремаль ситуациядә ничек дөрес эш итәргә һәм баланың үз адресын, ата-аналарының һәм ашыгыч хезмәтләрнең телефон номерларын белүенә инанырга тәкъдим итте. Чара барышында юл куркынычсызлыгына аерым басым ясалды. Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәре Ольга Аносова сөйләгәнчә, агымдагы елның 11 аенда балигъ булмаганнар катнашында 79 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 10 яшүсмер һәлак булган һәм төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган. Ул республикада яшәүче яшьләрнең юл хәрәкәте кагыйдәләрен тогәл үтәү зарурлыгын искәртте. «Балалар белән әңгәмә корырга һәм аларга юл куркынычсызлыгының гади кагыйдәләре турында искә төшерергә кирәк – беркайчан да светофор сигналларын игътибарсыз калдырмаска, машина юлы аша моның өчен билгеләнгән урыннарда үтәргә һәм машина юлы янында уйнарга ярамый. Моннан тыш, яктылыкны кире кайтара торган элементларны балалар киемнәрендә кулланырга кирәк, бигрәк тә төүлекнең карангы вакытында һәм күрү мөмкинлеге житәрлек булмаган шартларда, балалар юлда йөртүчегә күренеп торсын өчен», - дип ассызыклады ЮХИДИ (УГИБДД) вәкиле. Аннары ул ата-аналар үз балаларының игътибарын таудан машина юлына шуунын ярамавына һәм мондый күнел ачуларның нәтижәләренә юнәлтергә тиеш, дип остәде.
Эчке эшләр министрлыгының ОИиОС МВД житәкчесе Светлана Холодкова баланы дөрес һәм куркынычсыз тәртипкә өйрәтү өчен үзләренә тиешле үрнәк күрсәтергә кирәк, дип ассызыклады. Шулай ук яшүсмернең кайда һәм кем белән вакыт үткәрүен белү

моһим. «Кышкы каникуллар вакытында Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә балигъ булмаганнар тарафыннан хокук бозуларны һәм алар катнашындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтvгә юнәлдерелгән чаралар комплексы турында хәбәр итәсем килә», - дип билгеләп vтте ул.
Россия Тикшерv комитетынын тобәк идарәсе житәкчесенен олкән яр-дәмчесе Наталья Афанасьева бил-геләп vткәнчә, кышкы чорда урамда булганда куркынычсызлык кагыйдәләрен vтәргә кирәк. Температура vзгәрv, кар явып боз барлыкка килvгә һәм йортлар тvбәсеннән кар тошvгә китерә, шуна бәйле рәвештә куркыныч участокларнын киртәләре артына кермәскә, йортларнын стеналарына һәм подъездларнын козырекларына якын килмәскә тырышырга кирәк. Игътибар ителгәнчә, махсус жиһазландырылган тауларда гына шуарга момкин. Таулардан жиһазландырылмаган урыннарда, юл янында шуу куркыныч һәм торле жәрәхәтләр алуга китерергә момкин. Очрашу азагында спикерлар котелмәгән хәл булганда, бу турыда ашыгыч хезмәтләр телефоны аша 01, 101 яки 112гә хәбәр итәргә кирәклеген искәрттеләр.

**Н.ХӘЛИЛ**